/Җәй истәлекләре/

### Хезмәт төбе хәзинә

Җәй – зур мөмкинлекләр чоры. Ял озын, көннәр матур, вакытыңны гына файдалы уткәр... Мин дә ялымны үземчә файдалы үткәрәм. Иптәшем Аслан, абыем Илназ белән авыл хуҗалыгы тармагында эшләдек. Җәй башында хуҗалыкның ындыр табагын, амбар тирәләрен чүп-чардан арындырдык, ягъни тирәлегебезне чистарттык. Хезмәт җиңелләрдән түгел иде. Шулай булса да сынатмадык. Ул эшләрдән соң көтү көтәргә чыктык. 256 баш тана булган көтүне көтү – зур тырышлык, игътибар таләп итте. Ничек кенә булмасын, өстебезгә йөкләнгән хезмәтне җаваплылык белән үтәргә тырыштык, әлбәттә, сынатмадык. Хезмәт белән җәебез үтсә дә, без ныгыдык кына. Киләсе җәйләрне дә хезмәттә үткәреп, кесәбездә үзебез эшләгән акчабыз булуын телибез.

*Илдус Камалов, IX сыйныф укучысы*

/Безнең спорт/

Быелгы җәй пандемия шартларында узганлыктан, Сабан Туе бәйрәмнәре, төрле спорт ярышлары, күмәкләшеп табигатькә чыгулар оештырылмады. Шуңа да карамастан җәебез бөтенләй спортсыз узды дип әйтеп булмый. Чирмешәндә су коенулар, гаилә һәм дуслар белән велосипедта йөрүләр, сахрага чыгулар – барысы да булды. Гомумән алганда, авыл баласының бер көне дә хәрәкәтсез узмый инде ул.




Җәй айларында безнең мәктәп укучылары спорт ярышларыннан шахмат турнирларында катнаштылар. 1-нче июнь – “Балаларны саклау көне” уңаеннан Чистай шәһәрендә блиц шахмат төре буенча онлайн турнир уздырды. Анда безнең шахматчылардан **Гафиятуллин Фаил** белән **Хәйруллин Айназ** катнашты. Турнир нәтиҗәләре буенча, 2010-2011 елгы балалар арасында Фаил 1-нче урынга лаек булды.

Август аенда Чистай шәһәрендә ТАССРның 100 еллыгына һәм шәһәр көненә багышланган шахмат турниры үтте. Турнирда 2004-2012 елгы шахматчылар катнашты. Бу бәйгедә дә **Гафиятуллин Фаил** белән **Хәйруллин Айназ** үз көчләрен сынадылар. Турнир бик кызу үтте. Күп санлы спортчылар күнелле музыка астында берсеннән-берсе уздырып уйнарга тырыштылар. Нәтиҗәдә, 2009-2012 елгы малайлар арасында Фаил 1-нче, ә гомуми зачетта – 2-нче урынга, Айназ – 2004-2008 елгы малайлар арасында 3-нче урынга лаек булды. Әфәрин, егетләр!!!

30-нчы август көнне Аксубай районы яшьләр һәм спорт комитеты тарафыннан Татарстан Республикасы көне һәм ТАССРның 100 еллыгына багышланган турнир уздырылды. Ул Аксубай шахматчылары һәм кунаклары арасында үтте. Турнирда **Гафиятуллин Фаил** дә катнашты. Ул яшьләр арасында 1-нче урынны яулап, чираттагы грамота һәм медальгә лаек булды.

*Руфия Гафиятуллина, биология һәм инглиз теле укытучысы.*




17-нче август көнне хезмәттәшләребез Илдар һәм Алсу Сафиуллиннар гаиләсендә сөенечле вакыйга булды – уллар Ислам дөньяга килде. Барлык мәктәп коллективы исеменнән Илдар белән Алсуның шатлыкларын уртаклашып, чын күңелдән тәбрик итәбез. Хәзерге чорда авылда балалар бик сирәк туа, шунлыктан бу барыбыз өчен дә бик куанычлы вакыйга. Исламның иманлы, зиһенле, сау-сәламәт булып үсүен телибез. Гаиләсенә, туган җиребезгә, халкыбызга терәк булырлык чын ир-егет булып үссен. Әти-әнисенә аны тиң-тигезлек белән үстерергә насыйп булсын.

*Мәктәпнең профсоюз оешмасы җитәкчесе Рифкать Туктамышев*

/Котлыйбыз!/

20-нче июнь көнне мәктәбебезнең хуҗалык җитәкчесе **Шакиров Азат** абыйның 60 еллык юбилее булып узды. Азат абыйга алдагы тормышында балаларына һәм оныкларына терәк булып, исәнлек-саулык белән гомер итүен телибез!

Җәй айларында гомер бәйрәмнәре булы узган хезмәттәшләребез – **Насыйрова Гөлүсә** (24-нче июнь), **Гафиятуллина Руфия** (26-нчы июнь), **Сафиуллина Алсу** (16-нчы июль), **Сабитова Илсөяр** (8-нче август) апаларны туган көннәре белән тәбрик итәбез. Аларга исәнлек-саулык, гаилә бәхете, хезмәтләрендә уңышлар, озын гомер телибез!

Ямьле җәй көннәрендә дөньяга килгән бакча балалары **Җамалетдинов Фирдүсне** (2-нче июль), **Сафиуллина Гөлсемне** (9-нчы июль), **Нурматова Зәйнәпне** (29-нчы июль), укучылардан **Гафиятуллин Фаилне** (24-нче июнь), **Хөснуллин Маратны** (24-нче июнь), **Нурматов Мусаны** (6-нчы июль), **Җамалетдинов Зөлфәтне** (23-нче июль), **Галиуллина Айсылуны** (28-нче июль), **Залиев Салаватны** (6-нчы август), **Насыйрова Кәүсәрне** (18-нче август) туган көннәре белән котлыйбыз. Тәртипле, тырыш, максатчан булып үсүләрен телибез!

*“Мәктәп хәбәрчесе редколлегиясе”*





Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева
Виктория Нукина
Зөлфирә Сафиуллина
Сара Насыйрова
Рузилә Мөхәмматова


# Мәктәп хәбәрчесе


№4 (№17) август 2020 ел

Түбән Майна урта мәктәбе газете

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru


/Мөхәррир сүзе/

### Чисталык чүпләмәгән җирдә була

Авылыбыз матурлыгы, яшеллектә утырган урамнары, чисталыгы белән читтән килүчеләрне дә, килгән кунакларны да сокландырып тора. Туган җиребезнең гүзәллеге өчен авылдашларыбыз куйган көч беркайчан да эзсез калмас.



Әйләнә-тирә мохитны саклау һәркемнең изге бурычы икәнен барыбыз да аңлый кебек. Авылыбыз тагын да матурлансын өчен ел саен мәктәп хезмәткәрләре һәм укучылар белән берлектә мәктәп тирәсен генә түгел, урамнарны, болыннарны да чүп-чардан арындырып торабыз. Мондый өмәләр, гадәттә, язлар җитеп, җирләр кипкәч башкарыла. Тик бераздан, кызганычка каршы, авыл урамнарында, шул исәптән мәктәп тирәсендә дә, ташлап калдырылган ертык пакетлар, буш шешәләр пәйда була. Әлбәттә, аларны беркем дә читтән алып килеп ташламый. Шулай итеп, күпме генә җыештырып торсак та, булдырган чисталыкны саклау тагын да кыенрак диган нәтиҗәгә киленә.

Кайберәүләр урамга чүп-чарны балалар гына түгел, теләсә-кем ташларга мөмкин дия торгандыр. Ләкин туңдырма һәм чипсы пакеты, газировка шешәсе белән конфет кәгазьләре өлкәннәр кулыннан төшмәгән. Җәен авылга кайткан шәһәр балалары чүпләгән дисәк, алар гадәттә авылныкылар белән бергә йөриләр. Шәһәрдән кайтучыларда начар гадәт күрсәк, аларны кисәтергә барыбызның да хәленнән килә.

Һәр кеше үз өендә, ишегалдында, бакчасында һәм турысында тәртип булса гына канәгать яшидер. Бик тәрбиясез һәм түбән дәрәҗәдәге кеше генә азып-тузып беткән шартларда яши аладыр. Ә урамнар, болыннар, көтүлекләр һәм яр буйлары – барыбыз өчен дә уртак яшәү тирәлеге. Табигатьне саклау һәм җәмәгать урыннарын тәртиптә тоту кешедәге зыялылык, тәрбиялелек күрсәткече булып тора. Шулай булгач, дуслар, үз дәрәҗәбезне белеп яшәргә өйрәник!

*Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

### 30-нчы август – Татарстан Республикасы көне!



**Республика көне – һәр татарстанлы өчен иң мөһим бәйрәмнәрнең берсе. Күпмилләтле дәүләтебез халкының тынычлык, иминлек, бердәмлек бәйрәме ул.**

**Без төбәгебезнең байлыгы, аның меңьеллык тарихы белән хаклы рәвештә горурланабыз һәм шушы уңышларга ирешергә мөмкинлек биргән өлкән буын, аларның хезмәте, батырлыгы алдында баш иябез. Алар калдырган бай милли-мәдәни мирасны, туган телебезне сакларга, калебебез белән Ватанга тугры булырга тиешбез. Туган-үскән җиребезгә файдалы кешеләр булып үсик! Бәйрәм белән барыгызны да.**

/Рәсми хәбәрләр/

### Дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре

Узган уку елының соңгы чирегендә дистанцион укытуга күчүнең иң зур авырлыгы чыгарылыш сыйныф укучыларына төшкәндер. Чөнки алар мәктәпкә йөреп бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләнү мөмкинлегеннән мәхрүм калдылар. Аеруча 11-нче сыйныфны тәмамлаучы 5 укучының өчесе башка авылдан булу әзерләнү өчен зур кыенлык тудырды. Имтихан нәтиҗәләренә килгәндә, 11-нче сыйныф укучылары математикадан уртача – 58 балл, рус теленнән – 71, географиядән – 61, биологиядән – 53, информатикадан – 45 балл җыйдылар. Барлык фәннәр буенча уртача балл 57,6 % тәшкил итте. Ә мәктәптә уздырылган алдан сынау имтиханнарында баллар күпкә югарырак иде.

Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшырып, мәктәпне тәмамлаган укучылар төрле уку йортларына таралдылар. IX сыйныфны тәмамлаган укучылардан Әхмәтова Нәзирә Яр Чаллы шәһәренең технология техникумына, Панов Артур да шул калада программист белгечлегенә, Гыйззәтуллина Алия Чистай шәһәренең медицина көллиятенә укырга керделәр. X сыйныфтан киткән Шафиков Әнис Яр Чаллыдагы автомеханика техникумына, Залиева Илдеяр Чистайдагы күппрофильле көллияткә урнаштылар. XI сыйныфны тәмамлаган Гыйльметдинова Әлфинә Яр Чаллы шәһәренең медицина көллиятендә, Сафиуллина Динә Алабуга шәһәренең педагогика университетында, Әхмәтҗанова Лилия Казан шәһәрендәге ТИСБИга укыячаклар. Камалова Гүзәл Яр Чаллы шәһәрендә пешекче, Фәйзуллина Зөлфинә теш техникы белгечлеген алачаклар.

*Укыту эшләре буенча директор урынбасары Илдар Сафиуллин*

## Җәйге сәфәрләр

**/Безнең сәяхәтләр /**

Быелгы ел сәяхәт итү өчен бик кулай булмаса да, безнең гаилә өчен узган җәй кызыклы сәфәрләргә бай булды. Җәй дәвамында без берничә истәлекле урында булырга өлгердек. Башта гаиләбез белән Шәһри Болгарга сәяхәт кылдык. Аннан соң апамнар һәм җизнине күршедәге Биләрнең борынгы истәлекләре белән таныштырырга алып бардык. Ләкин минем өчен иң тәэсирлесе Фарит җизниләрнең туган ягы – Арча төбәгенә сәяхәт итү булды.

Казаннан Арча юлы белән киткәч, иң башта Иске Казан тарихи комплексына тукталдык. Биредә музей гына түгел, ә урта гасыр татар кирмәне тулысынча диярлек торгызылган. Бу каланың капкасыннан керүгә үк, элеккеге заманнарга әйләнеп кайткан кебек булдык. Музейда төрле борынгы экспонатлар, кирмәндәге XIV-XVI гасырлардагы шикелле төзелгән җил тегермәне, сак манаралары, ату кораллары нәкъ шундый тәэсир калдырдылар.



*Яңа Кырлайда Сәгъди абзый өе янында*

Музейдан соң без Иске Казанның элеккеге кала урынына юл алдык. Калага менү юлы буенда, тау битләрендә бу яктагы халык изге итеп кадерләгән чишмәләре урнашкан. Безнең яктагы Биләрдәге кебек, биредән дә кеше бер дә өзелми бугай. Иске Казан каласы бик биек тау башына урнашкан. Биредән тирә-яктагы күз күреме җирләрне күзәтергә мөмкин. Табигый тынычлык, саф һава, күзләрне иркәли торган хозурлыклар җанга сихәт бирә, күңелләрне рухландыра.

Арча шәһәрендә без Казан арты этнографик музее белән таныштык. Бу төбәкнең һәр почмагыннан татар рухы бөркелеп тора. Арча музее безне кабат шуңа инандырды.

Арча ягы татар халкына бөек шагыйрь Габдулла Тукайны биргән төбәк икәнен барыбыз да белә. Шул сәбәпле без Яңа Кырлай авылындагы Тукай музеена да керми китә алмадык. Музей белән танышканнан соң, авыл аркылы агучы Ия елгасының буасында көймәдә йөздек. Аннан соң Габдулла Тукай яшәгән Сәгъди абзый йортында да булдык. Бәләкәй Апушның бабасы белән утырткан нарат агачы шагыйрьнең үзе кебек бөек һәм мәгърур булып үсеп җиткән.

Сәяхәтебезне дәвам итеп, җизниләрнең авылы Сеҗегә киттек. Бу авылда чишмәләрнең күплеге таң калдырды. Икенче көнне төштән соң Сеҗенең кымыз ясала торган нәселле атлар фермасын карап йөрдек. Сенелем Кәүсәргә хәтта бәләкәй атка атланып йөрү бәхете тиде.

Гаиләбез белән бу сәфәрдән рухи азык, күңелле истәлекләр, җылы очрашу хәтирәләре белән кайттык. Чит илләрдәге кызыктыргыч матурлыклар үзебезнең янәшәдә дә бар һәм күп икән. Сәяхәттән туган ягыбызның бай тарихлы, гүзәл табигатьле почмакларын күбрәк өйрәнергә дигән максат белән дә кайттым.

***Сара Насыйрова, Х сыйныф укучысы***

**/Укучылар иҗаты /**

## Гөлбакча матурлыгы



Кеше табигать белән нык бәйләнештә тора. Ул кешенең эчке дөньясын үстерә, безне, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Табигатьнең искиткеч гүзәллеген тасвирларга сүзләр җитмәс иде.

Минем әни дә табигатькә бик бәйле. Ул матурлыкны күрә, аны ясый да белә. Табигый ямь белән генә чикләнмичә, зур бакчабызны матурлык дөньясы ясый. Әни чәчәкләрне бик ярата һәм аларны үрчетә. Безнең бакча – үсемлекләр дөньясы. Әнием үзе чәчәкләр янында күп вакыт уздырган, мин дә күбесенчә анын янында. Бакчада үскән чәчәкләр бик күп төрле. Алар бакчаны хуш исләр белән тутыралар, бал кортлары кунып, бал җыялар.

Быел әни чәчәкләрне авыл кешеләренә таратты. Димәк, авылымда гүзәллек артты. Әнием өләшкән чәчәкләрне авылдашларым үстерер, бакчалары чәчәк дөньясына әверелер. Хуҗалары да, сокланып үтүчеләр дә әниемә рәхмәт әйтерләр.

Әнием бакча белән генә чикләнми, өебезнең һәр почмагы яшеллеккә-гөлләргә уралган. Ул безне дә матурлыкны күрә һәм ясый белергә өйрәтә. Гүзәллек ул күңелеңне бизи, ди. Бакчабызда әле бик күп төрле чәчәкләр калды. Киләсе елларда да чәчәк өләшеп, башка бакчаларга да ямь өстәргә язсын.

***Виктория Нукина, IX сыйныф укучысы***

## "Сәләт"ле җәй

**/Җәй истәлекләре /**

Сәләт ул – белемгә, фәнгә тартылган, акыл-сәләтләрен төрле бәйгеләрдә күрсәткән укучыларны барлау һәм үстерү мохиты. Сәләт сүзен ишетүгә шатлыклы, яңа танышлар күп булган җылы җәй күз алдына килә. Чөнки мин дә быел бу лагерьга бару бәхетенә ирештем.

Туган авылымнан ерак булмаган бу лагерь Биләр авылы Хуҗалар тавы янында урнашкан иде. Барып керүгә һәркем шат йөзле, әйдаманнардан канәгать иде. Һәр катнашучы төрле аланлыкларга урнаштырыла. Мин "Зилант" аланына эләктем. Татар халкы әкиятләрендә һәм легендаларындагы мифологик образ исемен йөрткән аландагы иптәшләрем бик тиз дусларыма әверелделәр. Бер гаилә балалары кебек якынлан аралашып торгач, һава торышы яңгырлы булса да салкынын сизмәдек. Әйдәманнарыбыз безнең күңелне һәрдаим ни беләндер баетып тордылар. Кичке уеннар үзенә бер могҗиза иде. Оештыручыларыбызның безгә карата булган мөнәсәбәтеннән салкын көннәр һәм төннәр җылы булып тоелды. Хәтирәсе күп елларга барырлык тойгылар калды быелгы җәемнең бер атнасыннан.

***Рузилә Мөхәммәтова, Х сыйныф укучысы***

---

Якты кояшлы, җылы җиле, шау чәчәкле болыннары, яшеллеккә төренгән урманнары, татлы җиләкле, чалт аяз күкле җәй килде. Бу вакытны без, "Сәләт"тә булганнар һәм бер дә катнашмаганнар да сагынып көтә. Чөнки янә без шул аланга җыелабыз. Күптәнге танышлар да, яңалар да бирегә килергә ашкынып тора.

Сәләт! Күпме хатирәләр күз алдына килә. "Сәләт" – зур бер система. Монда сәләтләреңне ачу мөмкинлеге һәркемгә тигез бүленә. Бу лагерь 1994-нче елда татар телен белүче, олимпиадаларда җиңүчеләр өчен фән һәм югары технологияләр белән шөгыльләнү урыны булып барлыкка килгән. Шуннан бирле елдан-ел сәләтлеләрне җыя тора. Килүче һәр катнашучының нинди дә булса мөмкинлеген ачарга, юнәлешләр бирергә тырыша монда эшләүче әйдаманнар.

Без дә бу лагерьга янә  бару бәхетенә ирештек. Шул ук кәеф күтәренкелеге, шул ук чаткылар салалар күңелгә. Ел саен килсәк тә, тагын яңалык алдык. Оештыручыларга да, эти-әниләргә дә рәхмәт безнең җәебезнең күңелле истәлеге өчен.

***Зөлфирә Сафиуллина һәм Әминә Туктамышева, IX сыйныф укучылары***

**/Туган ягым – яшел бишек /**

## Алдагы  һәм Арттагы Гәрлинкә чокырлары

**"Алдагы Гәрлинкә"** һәм **"Арттагы  Гәрлинкә"** дип Югары кырның төньяк-көнбатышында урнашкан  тирән чокырлар атала. XVIII гасыр  ахырына караган авылның икътисади тасвирламасында *"овраги Горянки"* дип китереләләр. "Гәрлинкә" дигән атама русча "горлинка" (урман күгәрчене) яисә "горянка" (тауда яшәүче хатын-кыз) сүзләрен татарчалаштырып әйтүдән ясалган булуы мөмкин. Чокырларның урыслар яши торган Горка авылы җирләре белән чиктәш урында булуы да бу фикене куәтли.

Чокырларның  авылга  якынрак булганы Алдагы  Гәрлинкә дип  атала. Ул  Югары  кырдан кар сулары Чирмешәнгә агып төшүдән хасил булган 500 метр озынлыктагы һәм  5-7 метр тирәнлектәге  тирән ерымнан гыйбарәт. XVIII гасыр  ахырында бу ерым тоташтан урман эчендә торган. Хәзер дә Алдагы Гәрлинкәнең текә ярлары куе  чытырманлык белән капланган. Тарихи риваятьләр буенча, борынгы заманнарда бу чокырдан Биләр ханнары бакыр чыгарганнар. Чыннан да, чокырның урта бер өлешендә бакыр эретү өчен чимал булып торган кызгылт-көрән төсле комташ ятмалары бар.




Арттагы Гәрлинкә Майна башы урманының кар сулары ага торган елгадан гыйбарәт. Аның тирәнлеге Алдагы Гәрлинкәнекеннән күпкә артык, ләкин  ярлары сөзәк булганлыктан, артык сизелми. Бу чокыр да һәр  яктан урман белән  капланган һәм ярларында бик матур аланнар бар.

Гәрлинкә чокырлары тирәсендә известташ ятмалары күп. Үткән заманда халык шул ташларны яндырып һәм су белән изрәтеп төзелеш өчен измә әзерләгәннәр. Шуннан калган чокырларны Гәрлинкә тавы битендә хәзер дә күрергә була. Борынгы Биләрне өйрәнүче галимнәр шәһәрдә берничә дистә таш бина булганлыгын ачыкладылар. Әлеге биналарны төзү өчен ак ташны нәкъ менә безнең Гәрлинкә тавыннан чыгарган булулары да бик мөмкин. Чөнки Биләр тирәсендә башка таш чыга торган урын юк.

Гәрлинкә чокырлары элек-электән качкыннар яшеренеп ята торган урыннар буларак данлыклы. Гәрлинкәнең соңгы качкыннары булып Бөек Ватан сугышы елларында сугыштан качып кайтучылар торганлыгы билгеле. Сугыштан соңгы елларда Арттагы Гәрлинкә аланы колхоз умарталыгын тоту өчен файдаланылган.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***